ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«** 02 **»** 04 **2024ел** **№**400

«2011 елның 29 мартындагы БНФ/р/8/11/АРЗ санлы урман участогын арендалау килешүе нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы районы территориясендә линия объектларын урнаштыру» объекты территориясен чикләү проекты составында планлаштыру проекты проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы участок урманчылыгында, Бөгелмә урманчылыгында урнашкан линия объектлары территориясен чикләү проектын әзерләү турында»гы 2024 елның 26 гыйнварындагы 62 санлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. «2011 елның 29 мартындагы БНФ/р/8/11/АР3 санлы урман участогын арендалау килешүе нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы районы территориясендә линия объектларын урнаштыру» объекты территориясен чикләү проекты составында кушымталы планлаштыру проектын расларга.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина